РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«20» апрель 2022г. г. Альметьевск № 137

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 7 декабрендәге 1189 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 31 маендагы 242 номерлы «Әлмәт муниципаль районының бюджет елкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет елкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында (Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 30 октябрендәге 9 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет өлкәсе эшчеләренең хезмәт хакы айлык тариф ставкасыннан, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге, эш нәтиҗәләре буенча премияләр, еллык түләүле отпускны биргәндә матди ярдәм, сыйныф өчен йертүчеләргә айлык естәмә түләүләр, һөнәрләрне берләштергән өчен естәмә түләүләр, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үтәгән өчен айлык тариф ставкасыннан, шулай ук законнарга, муниципаль хокукый актларга туры китереп, эш бирүченең карары белән учреждениенең бурычларын һәм функцияләрен үтәүне исәпкә алып, законнарга, муниципаль хокукый актларга ярашлы бүтән түләүләрдән гыйбарәт;»;

1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче эшчеләрнең айлык тариф ставкалары күләмнәре Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә.»;

5 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) нормалаштырылмаган эш кене ечен хезмәт җиңел автомобильләре йөртүчеләренә өстәмә түләүләрне исәпкә алмыйча айлык тариф ставкасының 8 процентын күләмендәге катлаулы һәм киеренкелеге ечен айлык тариф ставкасына ай саен естәмә кертү;»;

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) айлык тариф ставкасының 8 проценты күләмендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр;»;

3 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) еллык түләүле отпускны бер айлык тариф ставкасы күләмендә биргәндә матди ярдәм.»;

5 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I сыйныф йөртүчеләргә - машина йөртүче сыйфатында эшләнгән вакыт ечен айлык тариф ставкасының 5 проценты;

5 пунктчаның еченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II сыйныф йөртүчеләргә - машина йөртүче сыйфатында эшләнгән вакыт өчен айлык тариф ставкасының 2 проценты;»;

6 пунктчаның еченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төнлә эшләгән ечен (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) - сәгать тариф ставкасының 7 проценты күләмендә;»;

6 пунктчаның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә нормалаштырылмаган эш кене ечен - айлык тариф ставкасының 10 проценты күләмендә.».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә. Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз кечөнә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук менәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советның Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Багманов И.Р.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»